**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан» и статью 7 Закона Республики Татарстан «Об обеспечении защиты жилищных прав граждан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
29 ноября 2017 года

## Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 25 июня 2013 года № 52-ЗРТ «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 6 (II часть); 2014, № 5, № 11 (I часть); 2015, № 12 (I часть); 2016, № 1 – 2, № 10; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 33 (I часть) следующие изменения:

1) часть 1 статьи 3:

а) дополнить пунктом $13^5$ следующего содержания:

«$13^5$) установление порядка обеспечения региональным оператором установления фактов воспрепятствования проведению работ по капитальному ремонту, в том числе недопуска собственником, лицом, осуществляющим управление многоквартирным домом, либо лицом, выполняющим работы по содержанию и ремонту общего имущества в многоквартирном доме, подрядной организации к проведению таких работ;»;

б) дополнить пунктом $13^6$ следующего содержания:

«$13^6$) установление порядка и срока представления лицом, осуществляющим управление многоквартирным домом или оказание услуг и (или) выполнение работ по содержанию и ремонту общего имущества в многоквартирном доме, либо региональным оператором (в случае, если собственники помещений формируют фонд капитального ремонта на счете регионального оператора) собственникам

помещений предложений о сроке начала капитального ремонта, необходимом перечне и об объеме услуг и (или) работ, их стоимости, о порядке и об источниках финансирования капитального ремонта общего имущества в многоквартирном доме и других предложений, связанных с проведением такого капитального ремонта;»;

2) в статье 8:

а) часть 1 дополнить пунктом $6^1$ следующего содержания:

«$6^1$) установку автоматизированных информационно-измерительных систем учета потребления коммунальных ресурсов и коммунальных услуг;»;

б) часть 2 после слова «собственники» дополнить словом «жилых»;

в) дополнить частью $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. Собственники нежилых помещений уплачивают взносы на капитальный ремонт на основании платежных документов (в том числе платежных документов в электронной форме, размещенных в государственной информационной системе жилищно-коммунального хозяйства), представляемых лицом, уполномоченным в соответствии с требованиями части 2 настоящей статьи, которое вправе представить платежный документ, содержащий расчет размеров взноса на капитальный ремонт на предстоящий календарный год, однократно в течение первого расчетного периода такого года. Собственник нежилого помещения вправе оплатить такой платежный документ единовременно в месяце, следующем за месяцем, в котором он представлен, либо ежемесячно равными долями в течение календарного года в сроки, установленные для внесения платы за жилое помещение и коммунальные услуги. В случае, если собственником нежилого помещения является юридическое лицо, платежный документ доставляется по адресу (месту нахождения) постоянно действующего исполнительного органа юридического лица (в случае отсутствия постоянно действующего исполнительного органа юридического лица – иного органа или лица, имеющих право действовать от имени юридического лица без доверенности), по которому осуществляется связь с юридическим лицом.»;

3) в статье 10:

а) пункт 5 части 4 после слов «услуг и (или) работ» дополнить словами «с учетом необходимости оказания услуг и (или) выполнения работ, предусмотренных пунктом 1 части 1 статьи 166 Жилищного кодекса Российской Федерации, одновременно в отношении двух и более внутридомовых инженерных систем в многоквартирном доме, определяемой нормативным правовым актом Кабинета Министров Республики Татарстан,»;

б) часть 10 дополнить пунктом 4 следующего содержания:

«4) в порядке, установленном нормативным правовым актом Кабинета Министров Республики Татарстан, определена невозможность оказания услуг и (или) выполнения работ по капитальному ремонту общего имущества в многоквартирном доме (в том числе завершения ранее начатых оказания услуг и (или) выполнения работ) в связи с воспрепятствованием таким оказанию услуг и (или) выполнению работ собственниками помещений, и (или) лицом, осуществляющим управление многоквартирным домом, и (или) лицом,

выполняющим работы по содержанию и ремонту общего имущества в многоквартирном доме, выразившимся в недопуске подрядной организации в помещения в многоквартирном доме и (или) к строительным конструкциям многоквартирного дома, инженерным сетям, санитарно-техническому, электрическому, механическому и иному оборудованию многоквартирного дома.»;

в) дополнить частью $10^2$ следующего содержания:

«$10^2$. Изменения в региональную программу капитального ремонта по основанию, предусмотренному пунктом 4 части 10 настоящей статьи, должны предусматривать плановый период оказания услуг и (или) выполнения работ по капитальному ремонту общего имущества в многоквартирном доме (в том числе завершения ранее начатых оказания услуг и (или) выполнения работ) после устранения соответствующих обстоятельств. Сокращение перечня планируемых видов услуг и (или) работ по капитальному ремонту общего имущества в многоквартирном доме по основанию, предусмотренному пунктом 4 части 10 настоящей статьи, не допускается.»;

г) часть 11 дополнить предложением следующего содержания: «Органы местного самоуправления обязаны утверждать краткосрочные планы реализации региональной программы капитального ремонта в случае, если это предусмотрено нормативным правовым актом Кабинета Министров Республики Татарстан, в порядке, установленном этим нормативным правовым актом.»;

д) часть $11^1$ дополнить пунктом 3 следующего содержания:

«3) актуализации в связи с проведением в порядке, предусмотренном частью 6 статьи 189 Жилищного кодекса Российской Федерации, капитального ремонта многоквартирного дома в объеме, необходимом для ликвидации последствий аварии, иной чрезвычайной ситуации природного или техногенного характера.».

**Статья 2**

Внести в часть 4 статьи 7 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 72-ЗРТ «Об обеспечении защиты жилищных прав граждан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2011, № 10 (I часть); 2012, № 11 (I часть); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 27 (I часть) следующие изменения:

1) слова «исполнителей коммунальных услуг (лиц, осуществляющих предоставление коммунальных услуг)» заменить словами «лиц, осуществляющих управление многоквартирными домами,»;

2) слова «, о состоянии расчетов потребителей с исполнителями коммунальных услуг» исключить.

**Статья 3**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан принять нормативные правовые акты, обеспечивающие реализацию настоящего Закона, в течение трех месяцев со дня вступления в силу настоящего Закона.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
14 декабря 2017 года
№ 89-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” Татарстан Республикасы Законына һәм “Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында” Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

## 1 статья

“Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле $13^5$ пункт өстәргә:

“$13^5$) капиталь ремонт эшләре үткәрүгә комачаулык итү, шул исәптән милекченең, күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы затның йә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы затның подряд оешмасын мондый эшләрне үткәрүгә кертмәү фактларын региональ оператор тарафыннан ачыклауны тәэмин итү тәртибен билгеләү;”;

б) түбәндәге эчтәлекле $13^6$ пункт өстәргә:

“$13^6$) күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы яисә хезмәтләр күрсәтүче һәм (яисә) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы зат йә региональ оператор тарафыннан (урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында булдырган очракта) урыннар милекчеләренә капиталь ремонтны башлау срогы, хезмәт

күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең кирәкле исемлеге һәм күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында тәкъдимнәр, мондый капиталь ремонт ясауга бәйле башка тәкъдимнәр бирү тәртибен һәм срогын билгеләү;";

2) 8 статьяда:

а) 1 өлештә түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

"$6^1$) коммуналь ресурслар куллануны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләрдән файдалануны исәпләүнең автоматлаштырылган мәгълүмат-үлчәү системаларын урнаштыру;";

б) 2 өлештә "очракта" сүзеннән соң ", торак" сүзен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

"$2^1$. Торак булмаган урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәрне әлеге статьяның 2 өлеше таләпләре нигезендә вәкаләтле булган киләсе календарь елга капиталь ремонт өчен кертем күләме исәпләнгән түләү документын бирергә хокуклы зат тарафыннан бирелгән түләү документлары (шул исәптән торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасына урнаштырылган электрон рәвештәге түләү документлары) нигезендә мондый елның беренче исәп-хисап чоры дәвамында бер мәртәбә түлиләр. Торак булмаган урын милекчесе мондый түләү документын ул бирелгән айдан соң килә торган айда бер мәртәбә йә торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү билгеләнгән срокларда календарь ел дәвамында ай саен тигез өлешләр белән түләргә хокуклы. Торак булмаган урын милекчесе юридик зат булган очракта, түләү документы юридик затның даими эшләүче башкарма органының (юридик затның даими эшләүче башкарма органы булмаган очракта, юридик зат исеменнән ышанычнамәдән башка эш йөртү хокукына ия булган башка органның яисә затның) юридик зат белән элемтәгә керү мөмкинлеге бирә торган адресына (булу урынына) җибәрелә.";

3) 10 статьяда:

а) 4 өлешнең 5 пунктында "сроклары" сүзеннән соң "Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган хезмәтләрне һәм (яисә) эшләрне бер үк вакытта күпфатирлы йортның йорт эчендәге ике һәм аннан күбрәк инженерлык системаларына карата күрсәтүнең һәм (яисә) башкаруның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актында каралган зарурлыгын исәпкә алып" сүзләрен өстәргә;

б) 10 өлештә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

"4) урыннар милекчеләренең, һәм (яисә) күпфатирлы йорт белән идарә итүче затның, һәм (яисә) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы затның мондый хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яисә) эшләр

башкаруга подряд оешмасын күпфатирлы йорттагы урыннарга һәм (яисә) күпфатирлы йортның төзелеш конструкцияләренә, инженерлык челтәрләренә, күпфатирлы йортның санитария-техника, электр, механика һәм башка җайланмаларына кертмәүдә чагылган комачаулык итүенә бәйле рәвештә күпфатирлы йортта хезмәтләр күрсәтүнең һәм (яисә) эшләр башкаруның (шул исәптән элек башланган хезмәтләр күрсәтүне һәм (яисә) эшләр башкаруны тәгәлләүнең) мөмкин булмавы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актында күрсәтелгән тәртиптә билгеләнсә.";

в) түбәндәге эчтәлекле $10^2$ өлеш өстәргә:

"$10^2$. Капиталь ремонт буенча региональ программага әлеге статьяның 10 өлешендәге 4 пунктында каралган нигездә кертелгән үзгәрешләр, тиешле хәлләрне бетергәннән соң, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтүнең һәм (яисә) эшләр башкаруның (шул исәптән элек башланган хезмәтләр күрсәтүне һәм (яисә) эшләрне башкаруны тәгәлләүнең) план чорын күздә тотарга тиеш. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең планлаштырыла торган төрләре исемлеген әлеге статьяның 10 өлешендәге 4 пунктында каралган нигездә кыскарту рөхсәт ителми.";

г) 11 өлештә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актында каралган очракта, җирле үзидарә органнары шушы норматив хокукый актта билгеләнгән тәртиптә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын расларга тиеш.";

д) $11^1$ өлештә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

"3) Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 6 өлешендә каралган тәртиптә күпфатирлы йортка авариядән соң зыяннарны, башка табигый яисә техноген характердагы гадәттән тыш хәлне бетерү өчен кирәкле булган күләмдә капиталь ремонт ясауга бәйле рәвештә актуальләштерү.".

**2 статья**

"Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында" 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 4 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) “коммуналь хезмәтләрне башкаручыларның (коммуналь хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы затларның)” сүзләрен “күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы затларның” сүзләренә алмаштырырга;

2) “, кулланучыларның коммуналь хезмәтләр күрсәтүчеләр белән исәп-хисапларының торышы турындагы” сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә бу Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 14 декабрь
№ 89-ТРЗ